**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

« 01 » февраль 2019 ел № 130

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 январендәне 8-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 196 санлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварендәге «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 32 санлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елның 1 февраленнән Тукай муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезенә 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. 2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 январендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 18 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 1 февралендәге 130 санлы карарына 1 кушымта

2019 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне китереп бирү | 2633,03 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1931,72 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1381,72 |
| **Барлыгы:** | 5946,47 |

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 1 февралендәге 130 санлы карарына 2 кушымта

2019 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кафенгә төрү | 500,00 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне китереп бирү | 2133,03 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1931,72 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1381,72 |
| **Барлыгы:** | 5946,47 |